Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян

7

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮЛЬ * 2022 * КАЗАН

Алмаз ХӘМЗИН

КҮҢЕЛЕМ МИНЕМ – «МЕРСЕДЕС»!

Әллә кем дә түгел үзем,
Ләкин кеше бит күрә...
Очраганда гел әйтәләр:
– Ай-яй, кызың – бай түрә!

– Министрлыктагы Хәмзина,
Минем кызым түгел, – дим.
– Шутишь, – диләр, – качырасың,
Түгелдер лә аннан ким!..

Улың чит илдә укыйдыр –
Байлар шунда укыта.
– Аларныкы Лондонда да,
Парижда да, Нью-Йоркта...

– Кече кызны кемгә бирдең,
Берәр "шишка"гадыр бит?
Байлар байларны ярәшә,
Хәерчене алмый бик.

Бер генә хатын белән дә
Тормыйсыңдыр үзең шәт?..
Бөтен байлар типтерәләр –
Шулай яшәве бик шәп!

Машинаң да дөньядагы
Иң кәттәседер әле?
Салаватныкыннан күбрәк –
Бишәү, җидәүдер әле?..

Хатыныңның хезмәт хакы
Күптер үзеңнекеннән...
Ничек качырасың аны
Салымчылар күзеннән?

Туган-тумачаларыгыз кем,
Кайда, нинди хезмәттә?
Безнең күк ярлы-ябагай
Түгелләрдер, әлбәттә?

Синең кебек шәп артисләр
Әнә ничек гөрлиләр?!
Хатыны белән түш терап
Җырлап акча көриләр.

Синең кебек язучылар,
Том-том китап чыгара.
Тышлыкларын алыштырып,
Шәп эшлиләр чумара!

– Тыңладым да, кешеләргә
Әйттем бер сүз: "Сез – дөрес!
Җәяү йөрсәм дә эшемә,
Минем күңел – "Мерседес!!!"

Валентин ДРУЖИНИН

ШОМБАЙ *болай диде...*

Хөрмәтле Чаян! Күптән түгел Coca-Cola үзенең Россиядән китүе турында игълан итте. Безнең санкцияләр заманында гадәти нәрсә шикелле. Тик шул ук вакытта бу – эпоха ахырының билгесе. Илдән газлы татлы су гына түгел, «ирекле» дөнья билгесе китә. Совет вакытында Көнбатышның тетмәсен теткән бер генә карикатура да бу эчемлек сурәтеннән башка чыкмый иде. Ә үзгәртеп кору чорында эстрададан Кока-кола турында җырлар яңгырый иде...

Д. ЗАҺРИЕВ

БӨГЕЛМӘ

Яңалык безнең Шомбайны шатландырмады:

– Кока-кола китәме? Жәл! – диде аксакал. **– Хәзер без тутыккан тимер савытларны нәрсә белән чистартырбыз инде?**

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

• Әгәр дә сез берни дә эшләргә теләмисез икән, киңәшмә җыегыз.

• Хатынга хуҗа булырга теләсәгез, аңа еш кына буйсына белегез.

• Гомер – ул җыр, ә үлем – аның кушымтасы.

• Акыл өчен мактаганга бары тик чибәр хатын гына чынлап шатлана белә.

• Телевизор – күз белән кабул ителә торган бердәнбер йокы даруы.

• Әгәр яхшы шигырь укыйсым килә икән – мин аны язам.

• Хаклы булган чакта еш кына шикләнәбез, ләкин бернинди шиксез ялгышабыз.

• Көннәр шундый озын, ә еллар шундый кыска!

(Фикер ияләре мәҗлесендә язып алынды)

Урманнарда утлар яна

Билгеле булганча, өч нәрсәгә озаклап карарга була: ул да булса ут януы, су агуы һәм башкаларның эшләве. Әгәр бу фикерләрнең соңгы икесе белән бәхәсләшүнең кирәге булмаса, ут турындагысына карата фикерләр бердәм түгел. Мәсәлән, янгынчылар берөзлексез нәни очкыннан зур янгын чыгу куркынычы турында тукыйлар. Ә менә гамьсезлеккә чумган гади халык кеше ихтыярына буйсынмас ул күренешкә җиңел карый. Балачактан канга сеңгән "шырпы уенчык түгел" гыйбарәсенә дә аның исе китми.

Янгын куркынычына иң битараф караучылар – бакчачылар. Уңыш өчен көрәш һәм ут, алар фикеренчә, тыгыз бәйләнештә тора. Алар узган елгы үләнне, кипкән ботакларны яндыралар, учак ягып һәм шашлык ашап сезонның башын һәм ахырын билгеләп үтәргә дә онытмыйлар. Һәм һәр ел саен еш кына бакча ширкәтләрендә җыелган взносларны түгел, ә янгын китергән зыянны исәпләргә туры килә. Ярый да бит бу афәт кеше корбаннарына китермәсә. Менә Яшел Үзән районының Атлашкино төбәгендә бакча йортында бер хатын зыян күргән, ә Казан янындагы Әки бистәсендәге дачада бер ирнең җансыз гәүдәсен тапканнар.

Янгыннар статистикасында урман яну очраклары аерым урын алып тора. Белгечләр фикеренчә, моның сәбәбе тулысынча диярлек – кеше саксызлыгы. Мондый янгыннарны сүндерү кыен – юллар юк, янгын гидрантлары урнаштырылмаган. Кеше факторыннан башка, монда урман хуҗалыгындагы хәл дә зур роль уйный. Еш кына урманнарның иминлеген күзәтүчеләр юк – хәзер инспекторлар саны элеккегә караганда биш тапкыр кыскартылган. Безнең мәңгелек бәла булган бюрократия дә үз өлешен кертә: мәсәлән, Амур өлкәсендә урманнар яна, ә күршедәге Хабаровски крае ярдәм итә алмый, чөнки бу бюджет акчасын максатсыз файдалану булып санала.

Узган ел Россиядә 10 миллион гектар урман янды. Безнең республиканы зур янгыннар әлегә читләтеп үтә – башка өлкәләрдән аермалы буларак, махсус хезмәт бездә яхшы җиһазландырылган. Ләкин Татарстанда да төрле хәлләр була. Урман янмаса, шәһәр корылмалары дөрли: мәсәлән, Чаллыдагы полимерлар склады, "Нэфис косметикс" акционерлык җәмгыяте һәм башкалар.

Күптән түгел Казанда элекке Алафузов театрында урнашкан "Созвездие-Йолдызлык" арт-резиденциясен ялкын камап алды. Бу бина биш ел ремонтта булып, 2020 елда гына ачылды. Реставрациягә республика бюджетыннан 750 миллион сум тотылды, һәм санаулы сәгатьләр эчендә бу миллионнарның көле күккә очты. Резиденциягә тагын реставрация ясалачакмы – билгесез. Элекке театр репертурына эләккән бу онытылмас тамашаның сәбәбен тикшерүчеләр ачыклаячак.

Кырыс статистика белдерүенчә, ел эчендә республикада 6 меңнән артык янгын булган. Афәт китергән зыян 360 миллион сум тәшкил иткән, 178 кеше һәлак булган.

Гражданнарның аңлылыгын көчәйтү максаты белән быел ут белән саксыз эш иткән өчен штрафлар берничә тапкыр арттырылды. Коры сабаклар яндырган өчен хәзер 3 түгел, ә 20 мең сум түләргә туры киләчәк, ә урман янгынының сәбәпчесе булганнарга ярты миллион сум штраф түләргә йә дүрт ел рәшәткә артында утырып чыгарга туры киләчәк. Рөхсәт ителмәгән урында учак ягу исә гамьсез хуҗаларга 30 меңгә төшәчәк. Бу кагыйдәләрнең үтәлүен техник прогресс җимешләре күзәтәчәк – күктә инде бакчачыларның һәр адымын күреп торучы квадрокоптерлар оча. Бу каты чаралар аз булса да янгын сүндерүчеләрнең эшен киметер дип ышанасы килә.

Людмила САФИУЛЛИНА



Валентин ДУБИНИН

Виктор ФЁДОРОВ

Владимир ТИХОНОВ

• • •

– Бабай, әкият сөйлә әле!

– Аз белсәң, тыныч йокларсың!

Шулай дип ул Интернетта “Хәйләкәр төлке” белән “Камыр Батыр”ның кыскача эчтәлеген табып, улының үтенеченнән котылды.

• • •

Әгәр дә никахны ЗАГСта ел саен озайтып була торган булса, кызык, ничек үзгәрер иде икән безнең тормыш...

• • •

Егет чәчәк кибетенә керә.

– Миңа бер бәйләм чәчәк кирәк иде...

– Рәхим итегез, бездә ниндиен телисез шунысын сайлап була. Сезгә кайсысын?

– Әй, мин белмим дә инде...

– Мин сезгә ярдәм итә алам. Ни өчен ачуланыштыгыз соң?

• • •

Ике хатын сөйләшә.

– Ирең элеккечә сәбәпсез көнләшәме?

– Юк, хәзер инде сәбәпсез түгел.

• • •

– Кадерлем, айфон бүләк ит әле миңа?!

– Яхшы! Ләкин бер шарт белән.

– Мин барысына да риза!

– Кредитны синең исемгә язабыз.

• • •

– Менә сезгә алты көнлек йокы дарыы.

– Ул кадәр озак йоклыйсым килми.

• • •

– Сез коньяк эчәсезме?

– Бик сирәк очракта гына.

– Ә шулай да, кайчан?

– Әгәр берәрсе сыйласа...

• • •

Ирләр һәрвакыт шуны белергә тиешләр: бай хатыннарның байлыгына зур салым салына.

Абау!

ЕРАК МЕТРЛАР

Россия өлкәләре арасында Татарстанның һәрвакыт беренчелеккә омтылуына карамастан, фатирлар мәсьәләсе монда да статистиканы боза. Торак сатып алу мөмкинлеге буенча республика бары тик 67 нче урында гына булып чыккан. Файдалануда булган 60 квадрат метрлы 6,3 миллион сумлык фатирны сатып алу өчен, уртача татарстанлыга ун ел акча җыярга кирәк. Шундый ук торакка Магадан өлкәсендә бары тик 2 елдан артык, ә Кабарда-Балкар Республикасында яшәүчеләргә исә үтә озак – 17 елдан да күбрәк кирәк икән.

"БАКЧА КАРАКЛАРЫ"

Татарстандагы бакча ширкәтләрендә бакчачыларның взносларын үзләштерергә теләүче ялган рәисләр барлыкка килгән. Моның ысулы бик гади: башта ялган гомуми җыелыш протоколы төзелә, документлар салым инспекциясенә тапшырыла, анда исә яңа рәис теркәлә. Ә аннан соң ширкәт рәисе, вәкаләтле шәхес буларак, төрле оешмаларга, шулай ук банкка да мөрәҗәгать итә ала. Әлегә ялган рәисләрнең эзенә төшү җиңел түгел, ә акча урлауны исбатлау тагын да кыенрак – чөнки җыелышлар да чынлыкта кәгазьдә генә уздырыла.

ТҮЛӘРГӘМЕ, ТҮЛӘМӘСКӘМЕ?

Казан медицина университетының урология кафедрасы мөдире пациентларга түләүсез операцияләрне акчага ясаган. Медик ханым стационар дәваланууда яткан кешеләргә кирәк операцияне бары тик түләү өчен генә ясарга була, дип хәбәр иткән. Аннан соң теләүчеләрне үз фирмасы тарафыннан арендаланган кабинетка юллаган. Анда алар белән түләүле хезмәт күрсәтү турында килешенү төзелгән. Тикшерүчеләр мондый 16 очрак булганын ачыклаганнар.

ТЫЛСЫМЛЫ БӘХЕТ

Нурлатта гүзәл затларга бәхет өләшүче һәм аларның бар мәсьәләләрен хәл итүче тылсымчы пәйда булган. Бушлай түгел, әлбәттә. Теләүчеләр җитәрлек булган, әмма беркемнең дә кулына бәхет кошы килеп кунмаган. Аның каравы, сихер остасы үзе катлаулы хәлдә калган — аны, мошенниклыкта гаепләп, алты елга тимер рәшәткә артына озатканнар.

ТӘМ-ТОМЛЫ ӨСТӘЛ ЯНЫНДА

– Сез аларны нинди диетада тоттыгыз?

Михаил МИХАЙЛОВ

ШӘП ӘЗЕРЛӘНГӘНСЕЗ

– Кибетегез искиткеч шәп икән! Сездә күлмәкләр бармы?

– Ә үзегез күрмисезмени?

– Сайларга ярдәм итегез инде.

– Үзегез нәрсә теләгәнегезне белмисезмени?

– Алайса, бәлки, менә монысындыр?

– Юк, ярамый, ул күргәзмә үрнәге, бердәнбер данәдә.

– Ә менә монысын киеп карарга ярыймы?

– Ярамый, таушалган киемне аннан соң ничек сатыйм?

– Ә күлмәкне тотып карарга, тукымасының нинди икәнен укып карарга ярыймы?

– Юк, упаковкасын бозуыгыз бар.

– Нигә үзегезне берни дә сатарга теләмәгән кебек тотасыз?

– Безнең хезмәт хакы күпме сатудан тормый — без шәрә окладта!

– Ә нигә сез шулкадәр күп?

– Чөнки эш күп, һәрбер сатып алучы йөзәр сорау бирә!

– Мөдирегезне чакырыгыз!

– Исәнмесез, мөдир мин булам. Сез дөрес мөрәҗәгать итмисез, сатып алучыларның сораулары – сатучылар карамагында, ә мин – өлкән менеджер!

– Шикаятьләр кенәгәсен бирегез!

– Тотмыйбыз! Ә теге асылынып торган нәрсә – ул муляж!

– Акылдан язарга мөмкин! Сез чынлап та бернәрсә дә сатарга теләмисез бугай!

– Зинһар өчен, дулкынланмагыз, сез – клиент, сез һәрвакыт хаклы, сезнең һәрвакыт берни дә сатып алмаска хокуклы...

– Булдырасыз, хөрмәтле студентлар, шәп әзерләнгәнсез, «Сатып алучылар белән эшләгәндә сатучыларның еш очрый торган хаталары» дигән лаборатор эш өчен барыгызга да зачёт куям! Чираттагы лаборатор эшкә әзерләнегез: «Сатып алучы берни дә алырга җыенмаган очракта аңа товарны ничек сатып җибәрергә...»

Ринат АБЗАЛОВ



Фәнзаман БАТТАЛ

ШИФАЛЫ ДАРУНЫҢ СЕРЕ

Касыймханның бозавы чирләп китә. Кадрәккә ветврач Лукушкинга килә. Врач бер кәлимә дә татарча белми. Ә Касыймханның урысчасы бөтенләй юк диярлек. Бозауның чирен ничек аңлатырга? Касыймхан үзенең бөтен талантын җигә: чирле бозавы кебек йөгереп китә дә, идәнгә авып, сыртына ятып, кулаякларын селкетә, тартыша, мөгри... Врачка моның кыланмышлары ошап китә. Әлеге хәрәкәтләрен берничә мәртәбә кабатлаткач, көлә-көлә тиешле даруны биреп җибәрә. Бозау ике-өч көннән терелә, хәтта үз ишләре белән сөзешә дә башлый. Касыймхан соңыннан авыл халкына болай сөйли:

– Акылымны җигеп, урыс брачка бәйнә-бәйнә аңлатып сөйләгән идем, шифалы дару эләкте!

ИҢ ШӘП КҮЗЛЕК

Әзһәр абый, Минзәләгә барып, окулистка керә һәм кәнәфигә эре генә утырып, күзлек сайлый башлый. Врач бер-бер артлы унлап күзлек кигертеп карый, әмма Әзһәр абый берсен дә ошатмый. Ачуы чыккан врач, аптырагач, пыяласыз күзлек кидертә моңа. Шунда Әзһәр абый, шатланып, урыныннан ук сикереп тора да:

– Менә бусы әйбәт күрсәтә, ичмасам! – ди.

...Әзһәр абыйның арт санында үртәлгән врачның сырлы табан эзе әле хәзер дә саклана, диләр, хак булса.

Александр БРЮХАНОВ

БАШ ЭЧЕНДӘ ШАКУ

Денис Сергеевич – ниндидер департамент башлыгы урынбасары – соңгы вакытта кичләрен эштә тоткарланып калган чакта баш авыртканын сизә. Һәм ул мондый гына авырту түгел, ә баш эчендә кемдер каты әйбер белән бәреп торган кебек.

– Барып җиттем бугай, – дип уйлап куйды ул, ләкин үзе ишек тоткасына да барып җитә алмады. Ә баш эчендәге шаку көчәйгәннән-көчәя барды.

– Нәрсә соң инде бу? – диде ул үзалдына һәм чигәләрен уып карады.

Кинәт баш эченнән тавыш ишетелде:

– Ярдәм ит...

Шундук шаку туктады.

– Нәрсә? Кем бу? – дип сорады Денис Сергеевич һәм тирә-юньгә карап алды...

– Бу – мин, хуҗа, – дип шакылдады сул чигәдән чәрелдек тавыш.

– Нинди хуҗа ди ул? – Денис Сергеевич, торып, ут кабызды, ләкин бу бернәрсәне дә үзгәртмәде...

– Башыңның хуҗасы... – диде чәрелдек тавыш, ләкин бу юлы инде уң чигәдән. Шаку тагын да көчәя төште. Аннан соң:

– Ай, ярдәм итегез, зинһар өчен... – дигән тавыш ишетелде.

– Нәрсә тагын шакылдыйсың инде? – дип, Денис Сергеевич чигәләрен уа башлады.

– Ул мин түгел, үзем генә булганда тыныч иде, ә хәзер монда ниндидер тараканнар килеп, мине бәреп төшермәкче булалар... – диде чәрелдек тавыш.

Денис Сергеевич, йодрыгы белән башына сугып куйды:

– Нәрсә соң инде ул анда?!

– Без хуҗа астында яшәүдән туйдык, ирек телибез, – диделәр башның төрле ягынннан тавышлар...

– Сез нәрсә телисез соң? – дип сорады Денис Сергеевич каты итеп.

Монда инде бөтен баш шаулый һәм әйләнә башлады, күпсанлы тавышлар яңгырады:

– Ашыйсыбыз килә! Сыра! Хатыннар телибез! Чит илгә барырга! Яңа машина!..

– Туктагыз, сез анда акылыгыздан яздыгызмы әллә? – дип җикеренде Денис Сергеевич. – Болар булсын өчен башта акча булырга тиеш, ә акча булсын өчен, күп һәм тырышып эшләргә кирәк...

– Мин аларга әйттем инде, – диде хуҗаның чәрелдек тавышы.

– Ә син мине кичләр буе эшләтмәкче буласыңмыни? – дип сорады Денис Сергеевич.

– Әлбәттә, кем эшләми, шул ашамый, – диде хуҗа.

– Җитте, моның белән берәр нәрсә эшләргә кирәк, – диде Денис Сергеевич һәм баш даруы эчеп куйды.

Чуашлар ядкаре

Һәр халыкның безнең Хуҗа Насретдинга охшаган үз каһарманы бар. Чуашларда ул Кукша Курття – Пеләш Григорий. Аны Казан губернасының Тәтеш өязендә XIX гасыр ахырында яшәгән дип сөйлиләр. Авыл бае Әхмәни һәм аның дусларыннан үткен теле һәм көлүе белән дан тоткан ул. Менә чуаш Насретдинының күпсанлы мәзәкләреннән кайберләре.

МӘЧЕЛӘР ҺӘМ ИРЛӘР

Пеләш Григорий урамда күршесе – Әхмәнинең кызы белән очрашкан.

– Нәрсә чистарткан самавырдай балкыйсың, Кулине? – дип сораган ул.

– Мантәләй яучылар җибәрәм диде, – дип хәбәр иткән шат чибәркәй.

– Кайчан әйтте инде ул моны сиңа?

– Бүген иртән генә.

– Бүген дисеңме? Димәк, мартта инде? Мартта барлык ирләр дә мәчеләр кебек, һәрвакыт өйләнергә сүз бирәләр.

НИЧЕК КИЛГӘН, ШУЛАЙ КИТӘР

Пеләш янына күрше авылдан баҗасы Туйтирәк кунакка килгән. Ишегалдына кереп туктау белән ул атын кыйный башлаган:

– Юньсез хайван! Кичтән үк күчтәнәчләр әзерләп, иртән баскычка чыгарып куйган идем. Арбага күчереп салырга өлгермәдем, ат чабып китте, үзем көчкә сикереп менәргә өлгердем.

– Тимә гаепсез хайванга. Монда буш арба белән килгән икән, китүен дә шулай китәр, – дип әйткән үз сүзен Курття.

БЕРКАЯ ДА КИТМӘ

Әхмәни иске коега егылып төшкән. Аның тавышын ишетеп, черек кое бурасы янына Пеләш килеп җиткән.

– Тартып чыгар мине моннан, Курття, – дип үтенгән бай.

– Ярый, йөгереп кенә бау алып килəм, тик кара аны, беркая да китмә! – дип кисәткән күршесе.

БЕР АЙДАН АГАРА

Әхмәнинең кызына яучылар килгән. Байның иркә кызына кияү ошамый, тик әнисе кызын ризалашырга үгетли.

– Нигә инде Сабанига чыгарга теләмисең? Менә диган кияү бит, үзе бай, үзе яхшы эштә! – дип сүгә ул үҗәт кызын.

– Бармыйм мин аңа, чәче җирән, – дип киреләнә кызы.

– Чәченә игътибар итмә син аның, синең белән яшәп бер айдан агара ул, – дип киңәш бирә урамнан узып баручы Пеләш.

ТИРӘН ЙОКЫ

Берзаман Пеләш янына баҗасы Туйтирәк килгән. Йокларга яткач, Туйтирәк аны җилкәсенә төртә:

– Курття, син йоклыйсыңмы?

– Нәрсә кирәк? – дип башын күтәрә Пеләш.

– Синнән бераз акча сорап тормакчы идем.

– Күрмисеңмени, күптән йоклыйм ич, – дип мыгырдый Курття һәм, стенага таба борылып, гырлап җибәрә.

БӘХЕТЛЕ КИЯҮ

Пеләш күршесе Әхмәнинең кызына гашыйк була. Яучылар җибәрә, ләкин кызын ярлыга бирергә теләми бай. Ә күрше авылдан бай малае кыз сораткач, Әхмәни уйлап та тормый. Кыз үзе дә бай кияү табылганына шатланып туя алмый.

Бернича елдан Әхмәнинең кияве көтмәгәндә авырып китә һәм дөнья куя. Ничектер Курття элекке кәләше белән очраша:

– Ярый әле сиңа өйләнмәгәнмен, – ди ул.

– Нигә? – дип сорый яшь тол.

– Синең ирең урынына миңа үләргә туры килгән булыр иде! – дип җавап бирә Пеләш.

Чуашчадан Евгений ТУРХАН тәрҗемәсе.

Анатолий НЫРОВ

САМОЛЁТ КАНАТЫ АСТЫНДА

Кадерле "Чаян"! Күңелгә якын урысча бер җырда мондый сүзләр бар: "Под крылом самолёта о чём-то поёт зелёное море тайги". Ә менә Лаеш районының Лесные поляны коттедж бистәсендәге йортлар шулай ук самолёт канаты астында икән. Шәхси кулда булган "СП Лаишево"ның кече авиация өчен очып китү полосасы нәкъ юл аркылы гына урнашкан. Мондый куркыныч якынлыкта газ корылмалары һәм электр үткәргечләр электән үк булган. Төзүче сүзләренә караганда, бу урынны төзелеш өчен сатып алган вакытта, рәсми документларда бернинди кече аэродромнар да күрсәтелмәгән. Оппонент исә үзенекен туглый, барысы да закон буенча эшләнгән, очу өчен корылган полоса җире промышленность һәм транспорт категориясендә, димәк, монда очарга ярый.

Һәр ике күрше әлеге килеп чыккан низагта бер-берсенә юл куярга уйламый. Ә ике арада бу җирләрне йортлар төзү өчен сатып алганнар кала. Бу хәлдән чыгу мөмкинчелеге хәтта кошлар очкан биеклектән дә күренми. Кайберәүләр ике куянны берьюлы ату ягында – төзелә торган йортларны кече авиацияне яратучыларга сатарга.

В. МӨШӘРАПОВ

Лаеш районы

КИПКӘН-БЕТКӘН КҮЛ

Хөрмәтле редакция! Кайсыдыр акыллысы әйткән: кеше ниндидер сәер зат – чүлдә чәчәкләр үстерә, кирәксә-кирәкмәсә күлне дә киптерә. Менә шул киптерүгә кагылган хәл Чебокса бистәсендәге күлгә туры килде бит әле. Аның суы 2019 елда ук саега башлаган иде. Кошлар да килми башлады, балыгы да бетте. Ул чагында экологик һәлакәтнең зурга китүенә бигүк әһәмият биреп бетермәделәр. Янәмәсе, күл ясалма җыелган, суы кырыендагы ярын һәм дамбасын яхшырту максатында җибәрелгән, төзелеш эшләре тәгәлләнгәч, барысы да үз урынына кайтарылачак. Ләкин әле эшләр һаман дәвам итә – күл юк.

Шул арада инде аның кондызлары да, кыйммәтле мехлы күселәре дә (ондатра) һәм күлдәге суны чыгарып-күтәреп җайлап торучы эшермә бикләре дә югалган. Аларны эзләп тә таба алмадылар, яңасын берәү дә эшләргә җыенмый – күл берәүнеке дә түгел, хуҗасы юк, балансга да тормый.

Шушы елларда кипкән күл иңкүлегендә нинди генә түрәләр, белгечләр булмады. Барысы да хәлнең катлаулыгына аһ оралар, күлне кабат торгызуга вәгъдәләр бирәләр. Тик менә әйткән сүзләре эш белән расланмый.

Казанның Чебокса бистәсендә яшәүчеләр.

Николай ВОРОНЦОВ

Василий АЛЕКСАНДРОВ

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Иң кирәкле кешеләр

Язның бер матур көнендә урамда ике дус хатын очраша.

– Кәримә, ни хәлләрең бар? Күптән күрешкәнебез юк. Нинди яңалыклар? Эшләр барамы?

– Сәлам, Гөлфия дустым! Күптән күрешмәдек шул. Эшләр баруы... ни дип әйтим инде? Киттем мин ул эшемнән.

– Ничек киттең? Ни булды? Син бит врач! Иң кирәкле кеше?!

– Ни булсын? Туйдырды! Көн саен шул авырулар белән эшләп, үзем авыруга әйләнә яздым. Киләләр дә зарланалар: теге җир авырта, бу җир авырта. Мин, әлбәттә, карыйм, сорашам. Аннары дарулар язам. Шуннан соң авырулар ризасызлык белдерә башлый: ник кыйммәтле дару язасыз? Арзанрагы юкмыни?

Үзең беләсең, безнең бит даруханәләр белән сөйләшеп куелган. Без рецепт язабыз, алар дару саталар. Кыйммәтлесен сатсалар, аларга да яхшы, безгә дә проценты бара. Бер зарплатага гына яшәп булмый, аңлыйсыңдыр?

– Аңлыйм инде, дускаем, аңлыйм...

– Әле кыйммәтле дару язганга баш табибка барып әләклиләр. Ул да безнең сыман. Аңа да акча кирәк. Шуңа түзә алмыйча, киттем мин сырхауханәдән. Хәзер эш эзләп йөрим. Сине очрату әйбәт булды, кибеттә эшлисең түгелме? Директормы? Миңа да берәр эш табалмассыңмы шунда?

– Табар идем дә... Киттем бит мин эшемнән...

– Абау! Шундый җылы урыннан кем китә инде? Ни булды? Син бит иң кирәкле кеше!

– Ни булсын? Шулар аркасында инде...

– Кемнәр? Ревизорлармы?

– Юк ла... Сатып алучыларны әйтәм. Башымны катырдылар. Кибеткә киләләр дә сораша башлыйлар: "Бу әйбер ник кыйбатланган? Суганнарыгыз артык эре. Итләрегез эсвижий түгел!" Әйтерсең мин ризыкны үз өемнән алып киләм дә сатам. Нindine җибәрәләр, шуны сатабыз инде... Дөресен әйткәндә, яхшырагын без арткарак алып куябыз. Башта булганын алып бетерсеннәр. Бигрәк азды халык. Әле картларны күрсәң, иртә таңнан килеп керәләр дә актарына башлыйлар. Болай да ташлама бәядән алалар, аңа яңа килгәнен генә бир. Шуңа түзмәдем, киттем.

– Хәзер нишләмәкче буласың?

– Әлбәттә, эш эзлим!

– Дустым, карале, мин нәрсә уйладым...

– Нәрсә?

– Без икебез дә бик кирәкле кешеләр. Мин сырхауханәдән киттем, син – кибеттән. Андый яхшы урыннарны каян табарбыз икән кабат? Үзең беләсең, табибка эләгү бик авыр. Син дә кибеттән юкка киткәнсеңдер дип уйлыйм. Аз булса да, ризыгы бар, акчасын алабыз. Әллә кире урыннарыбызга кайтыйк микән?

ҮЗАРА КАРАКЛЫК

Дөньяда иң зур криптопирамидага нигез салучыны 75 млн. сумга алдаганнар. Элек Үзәк Банк ArteryNetwork Corporation компаниясен кара исемлеккә урнаштырган, ә Роспотребнадзор аның сайтларын блокировкалаган. Кыска вакыт эчендә компаниягә нигез салучы Марк Богатыренкога ярдәмгә аның дәүләт каршында эшен акларга вәгъдә итүче «кызыксынган кешеләр» табылган. Бернichә ай тыгыз хезмәттәшлек эчендә хуҗа 1 миллион долларга якын акчадан колак каккан, тик нәтиҗәсен генә күрмәгән. Өметен югалткан пирамида төзүче хокук сакчыларына мөрәҗәгать иткән, алар җинаятьчеләргә «караклык» буенча җинаять эше кузгатканнар.

РИШВӘТ МӘКТӘБЕ

Ярославльнең бер мәктәбендә җәйге эш ата-аналарның прокуратурага мөрәҗәгать итү өчен сәбәп булган. Мәктәп укучыларына, мәктәп яны участогын тәртипкә китереп, 20 сәгать эшләргә кирәк булган. Эшләргә теләмәүчеләргә альтернатив вариант тәкъдим ителгән – сыйныф җитәкчесенә 300 сум бирергә һәм сентябрьгә кадәр азат булырга. Күп кенә ата-аналар, шул рәвешле, мәктәп кече яшьтән үк ришвәт бирергә өйрәтә, дип санаган. Уку йорты администрациясе, акча җыюга бернинди катнашы да юк, дип белдерергә ашыккан.

ЯШЕРЕН РЕМОНТ

Златоустта яшәүче бер ир-ат һәм машина карагы безнең ил машиналарын бик хөрмәт иткән. Гаражларның берсесен ачкач, ватык «пятнашка»ны күреп алган, машина карагы ай буе гаражга эшкә йөргән шикелле килгән һәм машинаны рәткә китергән. Автомобиль йөри башлагач, ул аны урлап качкан. Каракны очраклы рәвештә тоткарлаганнар. Ул үзенең яңа төзекләндерелгән карлыгачында документсыз йөргән.

«КОЙРЫКЛЫ ПЕЧКИН»

Дөньяда беренче мәче почтасын Санкт-Петербургта эшләтеп җибәрергә җыеналар. «Республика Мәчеләре» кафесы базасында койрыклылар хат ташучы һөнәрен үзләштерәчәкләр һәм сувенир открыткалары китерәчәкләр. Фикер яңа түгел – мәчеләрне почта хезмәтенә өйрәтергә омтылып караганнар, тик практикада мыекбайларның бер өлеше даими рәвештә үз сменасын йоклап калган, ә икенче өлешен даими рәвештә этләр куып йөргән. Бу юлы мәчеләрне этләрдән сакларга ниятлиләр, тик заказны көткәндә ул йоклап китә икән, аны беркем дә уятмый – икенче «почтальон»ны ярдәмгә чакырачаклар.

Константин МАЛЬЦЕВ

Виктор ФЁДОРОВ

Михаил ЛАРИЧЕВ

Абруйлы якташ

Дамир МОРТАЗИН

Студент Газизов уйга батты. Нишләргә? Менә ул тиздән дипломлы укытучы булыр, ә туган авылына кайтырга аның бер генә дә теләге юк. Уку дәверендә Казанга бик нык күнекте шул ул! Монда күңеленә охшаган бар нәрсә дә бар – төнге клублар, парклар, сәүдә үзәкләре, хәтта музейлы театрларына хәтле… Аннан соң кемнәр генә яшәми! Депутатлар, артистлар, җырчылар, шагыйрьләр – барысы да авылдан чыккан!

"Шагыйрьләр, шагыйрьләр…" дигән уй җәелеп китте Газизовның башында. – "Мин дә бит мәктәп стенгазетасына шигырьләр язгалый идем, директорның да мактап алгалаганын хәтерли… Менә тотам да шагыйрь булам".

Атна-ун көн узды микән, ул берничә баллон сыра сатып алып, тулай торактагы дусларына шигырьләрен укып күрсәтте. Тегеләрнең шаккатудан күзләре маңгайга менде. Бигрәк тә кызларныкы. "Редакциягә мөрәҗәгать итәргә кирәк!" дигән карарга килде ул.

"Шәһәр яңалыклары" газетасының редакциясендә яшь шагыйрьнең һаваланып шигырь укуына бик исләре китмәде – шигырьләрен кире үзенә кайтардылар.

– Бик борчылма, уңышсызлыклар иҗатчының рухын ныгыта гына! – диделәр дуслары. – Анда аларның үз мафиясе… Син хәтта бөекнең үзеннән дә уздырып язасың… – дип, җирле классик шагыйрьнең исемен атадылар.

– Бу яхшы идея! – диде дә Газизов, маңгаена кулы белән чәпелдәтеп куйды.

Озак та үтмәде, яшь талант "Кичке шәһәр" газетасы редакторының кабинетында утыра иде.

– Мин тегеннән… – һәм танылган бөек исем-фамилияне атады.

– Бик хуш, – дип куанычын яшермәде редактор.

– Безнең хөрмәтле мэтр үзе килә алмады – бик әһәмиятле вә дә җитди командировкада… Менә сезгә шигырьләрен тапшырырга үтенде… – Газизов аңа күк төстәге конвертын сузды.

– Бик тә куанып, бик тә… – сөенеченнән балкып әйтте бу сүзләрен редактор.

Газизов тиз генә икенче конвертны сузды – монысы – ак.

– Бусында минем шигырьләрем… – диде ул уңайсызланыбрак. – Шагыйрь абзый боларына да зур игътибар итәргә кушты…

Ак конверттагы шәп дип аталган шигырьләр редакторны әллә ни шаккатырмадылар. Ә менә күк конверттагылары сокландыргыч иде.

– Нинди талант! Нинди тирәнлек! Болар бит Тукай, Дәрдмәнд белән чагыша…

Күк конверттагы шигырьләр шундук "Мәңгелек шигъри юллар" сәхифәсе астында биреллделәр. Икенче көнне, әле генә чыккан газетаны тотып, яшь шагыйребез редактор кабинетында пәйда булды.

– Гафу итегез, – дип башлады ул сүзен дерелдәгән тавыш белән. – Мин конвертларны бутаганмын… Күк конверттагысы минекеләр иде…

Редактор катып калды.

– Сез борчылмагыз инде. Минем сезгә үпкәм юк… Искәрмә генә бирегез, янәмәсе, "Мәңгелек шигъри юллар" сәхифәсендә Газизов шигырьләре басылган…

Төзәтмәне бирделәр. Газизов теләгенә иреште. Аның шигырьләрен бастылар. Хәзер ул шундый җыентыклар белән редакцияләргә йөри, әкренләп танылган шагыйрьгә әверелеп бара, ни дисәң дә, аңа бит әдәбият алласыдай саналган даһи Үзе фатихасын биргән. Әлбәттә, туган якларына кайту турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Ә шулай да, туган авылы музеенда аңа – талантлы якташларына багышланган аерым зур урын әзерләнә. Ни әйтсәң дә, ул бит аларның үзләрен Казан хәтле Казанда зурлаячак…

БАЗАР ХИКМӘТЛӘРЕ ЯКИ КЕМ ХӘЕРЧЕРӘК?..

Үткән елның декабрьләре – халыкның иткә дигән малларын суя башлаган мәлләре. Мин дә бер көнне яңа суйган 1-2 кило ит алыйм әле дип, Колхоз базарына барган идем. Ит бик күп, сайлап алырга була. Мин инде олы кеше – яшьрәк, йомшаграк итләрне карап йөрдем. Бер хатын шунда игътибарымны җәлеп итте.

– Менә, бабай, кичә генә суйган бер яшьлек үгез ите, – ди бу. Миңа бик сөякле булмаганрак ике килолы кисәген үлчәп бирде. Шунда, итләр янындарак, каз күкәенә охшаган нәрсә ята:

– Ә бу нәрсә? – дим.

– Ул үгезнең теге нәрсәсе, алыгыз, бик тәмле, аны кыздырып ашыйлар, – ди.

Мин дә:

– Ә моның озын җире кая соң, комплекты белән бирсәң алам, – дигән булдым.

Ул кызарып куйды. Ә күршедәге сатучылар шаркылдап көлештеләр.

Татар халкы андый нәрсәләрне этка ташлый бит югыйсә. Хәзер тавык аягын, башын да саталар. Татар аны да ашамый, аягы тәрегә охшаган дип. Хәзер башының да йонын йолкып саталар. Бераз беркатлырак кешегә дә бит, "и тавык мие ашаган нәрсә", дип әйтәләр иде. Очсыз булгач алалар, ашыйлар. Фәкыйрьләр күбәйде илдә.

Якындарак кына тагын бер хатын сыер ите сата. Янәшәдә күп итеп маен өеп куйган.

– Сеңлем, бераз май бирегез әле, элек бушка иде ул, мин өй тәрәзәсенең тышкы ягында җимлек ясап куйган идем, песнәкләр шунда килеп ашыйлар аларны, карап тору миңа да зур куаныч, ләззәт бирә. Ә тавык сөякләрен җыеп, Крутушкада булган кызымның бакчасына барганда халыкны көтеп торып каршы алучы этләргә бирәм. Алар да безнең шикелле җан иясе бит. Күз яшьләрен агызып елыйлар – кызганыч. Үзебез дә эт хәлендә – аңлыйбыз. Дөрес, кайберләренең зыяны да бар. Шәһәр җирендә өерләре белән кешеләргә ташланган очраклары да булгалый. Такташ әйтмешли: "Килер бер көн, хәерчеләр эш эзләрләр төркем-төркем..." Эш эзләп кенә калсалар ярый да бит, хуҗаларына ташланырга мөмкиннәр, этләр кебек. Аллам сакласын!

Хөкүмәт баш вата да инде ватуын, ләкин нишләргә белми. Фатирларында эт асраучылар шактый. Зурлары да, шәркә кебек кечкенәләре дә бар. Берзаман шәһәр башлыгы Камил Исхаков аларны кеше саны итеп чутлап, коммуналь түләүгә кертергә тәкъдим белән чыккан иде, кабул итмәделәр, алар бит лифтта йөри, яннарына чит кеше керә алмый. Хәер, хәзер бер лифтка ят кеше белән бергә үзебезгә дә керергә куркыныч. Бу мәсьәләдә халыктан сораштырулар да алып бардылар. Әмма төрлесе төрле фикердә. Нужали берәү дә җиңә алмас инде бу этләрне дигән уйда йөрим. Эт хәле, эт вирусы кешегә күчә торган булып чыкмасын тагын.

Борчылып, 86 яшьлек Сөләйман бабагыз ШАКИРОВ.

Иван ХАНТИМЕРОВ рәсемнәре

«Чаян», 1981 ел.

Америка инструкторы:

– «Бәйсезлек» дигән сүздән соң штык белән чәнчибез, «азатлык» сүзеннән соң приклад белән бәрәбез!

«Чаян», 1982 ел.

– Их, элек менә нинди сугышлар булган бит – утыз еллык, йөз еллык...

Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Хатын иреннән сорый:

– Кадерлем, синең тормышыңда иң бәхетле биш ел кайчан булды?

– Башлангыч сыйныфларда укыганда.

• • •

"Макдоналдс" хәзер ничек дип аталса да, барыбер, иң әһәмиятлесе – бәдрәфләр яңадан ачыла.

• • •

– Хәтерлисезме, 2012 елны ахыр заман булырга тиеш иде бит?

– Әйе, әйбәт заманнар бар иде!..

• • •

Әй, официант, биредә ярты сәгать көтеп утырам инде.

– Ә мин иртәнге җидедән бирле, шулай да зарланмыйм бит.

• • •

– Доктор, бүтән сезгә дәвалаганыгыз өчен түли алмыйм, акчам бетте.

– Әйбәт бит инде сәламәтләнгәч!

• • •

Халык тарафыннан сайланып, кеше үзен күктән төшерелгән дип уйлый башлый икән – авыр заманнар килер.

• • •

– Ул начар табиб.

– Нигә?

– Кибеттә үзенә коньяк сатып алганын күрдем!

• • •

Кызлар, кыйммәтле автомобильләр, учлап-учлап акча бирүче бай ирләр турында хыялланган идегезме? Хыялларыгыз тормышка ашты! Безнең автосалонга кассир кирәк!

• • •

Зираттагы кабер янында бер ир елап тора.

– Нигә дөньядан шулай иртә киттең?!

Аннан сорыйлар:

– Ул сезнең туганыгызмы?

– Юк, ул хатымның беренче ире.

Валерий ТАРАСЕНКО

Игорь КИЙКО

Александр ШУЛЬПИНОВ

ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

Александр АЛЁШИН

• • •

Бер ханым теш табибына керә. Табиб моның авызын ачып карый да:

– Сезнең бөтен тешләрегез таза-сау. Тагын ни кирәк? – ди.

Хатын алтыннарын балкытып елмая:

– Теш дәваларга түгел, шушы хәзиналәремне саклау өчен авызыма сигнализация куя алмассыз микән дип килгән идем, – ди.

Сергей АНДРИАНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

Теш михнәтләре...

Элегрәк булган хәл. Теш сызлый башлап, үләр дәрәҗәгә җитмичә табибка бармыйсың бит инде. Көннәр, айлар, еллар үтә, теш сына-чери, каныйшешә, тамырга гына калып урт итенә күмелгәч кенә сызлавына чыдар әмәл калмагач, дөнья белән хушлашырга әзер булып, хастаханәгә юл тотасың. Күз алдына әллә нинди уйлар килә: дөньяны соңгы тапкыр күреп каласың кебек. Кешеләр дә ягымлырак тоела... Алар бик күп иделәр бит әле. Ләкин менә врачлар рәхимсез сыман. Сузып салырлар караватларына, берсе аягын шул караваት кырыена күтәреп басар да: "Йәле, авызыңны ач!" – дияр. Икенчесе башны тотар... Электән калган күренешләр бу. Ул вакытта да бер тешне суырткан хәтердә. Үтереп сызлагач барган идем инде. Наркоз дигән нәрсә булгандыр безгә 18 яшь чакларда да. Чират. Кабинетларыннан кереп китүчеләрнең: "Ай-й!" – дип җан өзгеч чинаулары ишетелгәләп куя. Шул чакта көтеп утыручыларның йөрәкләре аяк табанына төшеп китә. Үземнеке дә шулай булды. Чиратның яртысы каядыр югалды – качтылар бугай. Менә шул чакта тешемнең сызлавы да басыла бит әле. Телең белән хәлен белергә теләп капшап карыйсың... Урынында. Күңелгә "әллә мин дә кайтып китим микән" дигән уй килә. Юк, үлсәм үләм, керәм – хушыгыз!

Бүлмәдәге хәлләр мин уйлаганча ук түгел икән түгелен. Теш суыручы да минем уемдагыча андый юан, йон беләкле түгел. Аягын да махсус креслога күтәреп куймады.

– Хәзер, хәзер, бераз түзәргә туры килер инде, – дип, ягымлы тавыш белән күңелгә җылылык кертте. – Авызыңны зуррак ач! – диде дә, кулына тоткан чүкече белән нindидер зубило сыман мединструмент тыгып, чатнатып җибәрде. Башларым зыңгылдап куйды. Бәлки бу турыда куркытып язарга да кирәк түгелдер, әмма ул заманнардагы теш мәсьәләсе шулайрак хәл ителә иде. Аннары нindидер ыргак сыман нәрсә белән кисәкләрен чүпли башлады. Шөкер, соңыннан миннән дә бәхетле кеше юк иде.

Ярый, монысы шулай булды. Икенче очрак. Байтак еллар үткәч тагын бер тапкыр бу хәсрәтне кичәргә туры килде. Әйтәләр: хәзер теш алдыру пүчтәк – авырту сизелми дә дип. Шулайдыр да, әмма әле минем теге очрак һич онытырлык түгел, һаман да йөрәктә ярасы калды.

Бардым стоматологиягә. Матур гына бер ханым, җайлап кына сөйләшеп, кәкре-бөкре махсус караватка яткырды да, җайлап-майлап сүз башлады.

– Хәзер укол салырбыз, сизми дә калырсыз, тешегезне алырбыз, – дип җырлап, авызны ач-

тырды. Мамык кыстырды. Тагын ниләрдер маташтырды да:

– Укол салдым, бераз көтеп торыгыз, – дип, янәшәдәге бүлмәсенә кереп китте.

Утырам сынап: тел белән уколының тәэсирен тикшерәм. Бернинди үзгәреш тоймыйм. Уйлыйм: "Бу бит инде хәзер чыга да минем тешне урты-ние белән умырып ала".

Эч поша – күрәселәр бар икән. Сау булыгыз, туганнар һәм дөнья!.. Ханымны чакырам:

– Сезнең бу наркозыгызның тәэсире юк, ахрысы? – дим.

– Хәзер карыйбыз аны, – ди бу. Төрткәли нәрсәсе беләндер... – Авыртамы?

– Юк, – мәйтәм.

Тагын төртә, ныграк баскалый. Тагын, тагын...

– Алай икән, – ди бу, яңадан бүлмәсенә кереп китте...

Мин уйлыйм: "Кабат укол ясарга исәбе, ахрысы", – дип.

Озакка китте. Чыкмый да чыкмый... Түзәм. Ниһаять:

– Хәмзин, нишләп һаман утырасың, мәрткә киттеңме әллә? – ди.

– Сезне көтәм, – дим, – тешне алырга кирәк бит инде!

– Соң, алдым ла инде, әнә карагыз, янәшәдәге тәлинкәдә ята.

Карасам, шаклар каттым... Киләсе кысылган тешем: "Котылдыңмы инде миннән, рәхәт яшә!" – дигән сыман рәнҗеп ята.

– Кызганыч, әмма синсез кыенрак булыр гомер итүләре, газизкәем! – дидем дә, миһербанлы теш табибәсенә рәхмәт әйтеп, урамга ыргылдым.

• • •

Ике таныш очраша.

– Нәрсә булды сиңа?

– Берьюлы ике тешне суырттым.

– Тукта, әле бүген иртән генә бер тешем сызлый диган идең. Нигә икене алдырдың?

– Табибның кайтарып бирергә акчасы булмады.

РАФИС КОРБАНГА – 65!

Зур язучы –
Рафис Корбан!
Ул тугандук
Уйлар корган:
– Үскәч, – диган –
Әдип булам!
Шаккатсыннар...
Нинди әйбәт
Кеше туган!

Калын-калын
Китапларын
Укып халык
Хәйран калыр!
Даны биек
Инде аның
Зенитында
Иҗатының!

– 65 яшь
Хәзер Сиңа?!.
Башың төкле,
Минекедәй
Такыр түгел –
Хиросима...

Алмаз ХӘМЗИН

Разил ВӘЛИЕВ
Рафис Корбанга

"Уян, татар!" дип җыр язган,
Бик күп эшләр кырган ул.
Гомер буе ил сагында
Гомер буе тел сагында
Торган милли корбан ул,
Безнең Рафис Корбан ул!

Роберт МИҢНУЛЛИН
Балалар шагыйре
Рафис Корбанга

Балалар шигърияте дә,
Сәнгать төсле,
Сорый корбан.
Шундый корбаннарның берсе
Балалар өчен яза торган
Рафис Корбан.

Рафис Корбаннан дусларча эпиграммалар

Рәмис Аймәткә
Мәхәббәт дип, яратам дип
Язганнарың бик әйбәт!
Кемне шулай яратасың,
Әйтсәңче шуны, Аймәт?

Рабит Батуллага
Күпләр сиңа җитә алмый,
Никадәрле йөреп тә.
Бөтен хикмәт сакалда шул,
Бөтен хикмәт бүректә!

Башына папаха киеп
йөри башлаган
Данил Салиховка
Батулладан күрмәкче,
Бөек булып йөрмәкче.
Алтын икән акылың,
Ә кая соң сакалың?!

Марат Закирга
Сиксән битлек китабы бар,
Яңага түкми көчен.
Шул китап та ярап тора
Консультант булыр өчен.

Зиннур Мансуровка
Яза торгач булдың тәмам
Зур бүләкләр иясе.
Иң зур даның шул – син хәзер
Тукай энциклопедиясе.

Равил Кукушкин-Рахманига
Шигъриятта кем булсаң да,
Хет Тукай бул, хет Пушкин,
Балалар шагыйре дигән
Мөһер сугар Кукушкин.

Факил Сафинга
Факеллар элек Әлмәттә иде,
Якты яндылар, әлбәттә инде.
Бер генә Факил торып калды да,
Ансы да хәзер яна Чаллыда.

Фатих Котлуга
ТЮРКСОЙны ябып кына
Мөмкин түгел котылу,
Төрек – татар арасында
Күпер хәзер Ф. Котлу.

Тәлгат Абдуллинга
Фатир биреп, йортлы итте
Ул Казанның ярты халкын.
Мескен халык гомер буе
Түли хәзер шуның хакын.

Гомумән язучыларга...
Язучылар бетте тәмам
Сыегаеп, вакланып.
Эпиграмм язарга да
Язучы булмый табып.

Үзенчәлекле очрашу

Кемнәр генә кайда гына очрашмый хәзер. "Бер күрешү – бер гомер" диләр бит. Хак сүзләрдер. Һәм менә без дә, авылыбыздагы сигезьеллык мәктәпне тәмамлаган сабакташларым белән, кырык биш елдан соң авылдагы тулы булмаган урта мәктәп бинасында кабат бергә җыелырга тиешбез икән. Дөрес, сыйныфташларымның егерме биш, утыз ел узгач та җыелышып алганнарын ишетеп белә идем. Үзем дә чакыру алдым. Бабайга печән чабарга кайтып китепме, әллә башка сәбәпләр килеп чыгыпмы шунда, мин ул вакытта да кайта алмый калдым. Ә менә бу юлы өч көн алдан юлга чыктым. Аннары әти дә исән бит әле. Туксанны тутырып килә. Аның янында да озаграк тору иде исәбем.

...Менә мин, беренче сыйныфка җыенган укучы сыман, кыенсынып кына капка төбенә чыгып бастым. Сәгать ун тулып килә, йөрәк тә дөп-дөп тибә дигәндәй. Урам буйлап безгә таба бер хатын-кыз атлый. Исәнләшәбез.

– Фәргать, син түгелме соң бу? – дип сорады хатын.

– Мин.

Без тешсез хатын белән кочаклашып күрештек. Аның алга таба "Ничек хәлләр?", "Кайларданиләр җимереп ятасың?" кебегрәк сораулар яудырасын чамалап:

– Гафу итегез, мин сезне танымадым, – дидем. Ул авызын янә кулы белән каплап көлгәндәй итте дә:

– Мин бит синең классташың Фәһимә, – ди. – Тешләр куйдырып йөри идем әле, – ди. Аннары:

– Син элек тә шундый шаян-шук идең һәм хәзер дә дип, күзләремә текәлеп карады. Янып торган төпсез зәп-зәңгәр күзләр чыннан да аныкы иде. Йөзләргә елмаю иңде. Без күңелдәге хатирәләрне искә төшерә барып, нәкъ элеккечә, ашыкмый гына, сөйләшә-көлешә мәктәпкә таба атладык. Ә анда сыйныфташларның күбесе җыелып беткән, ни турындадыр гәпләшәләр, оештыру мәсьәләләрен хәл итәләр иде бугай.

Сыйныфташлар белән без дә төсле ташлар җәелгән, янякларына төрле чәчәкләр утыртылган сукмактан узып, шул урынга, ягъни ял итү почмагына, төрле төсләргә буялган эскәмияләргә барып утырдык. Нәкъ элеккечә, кызык та, рәхәт тә. Йөз-бит, килеш-килбәткә игътибар итмәгәндә, күз карашлары, сөйләм теле, холык-фигыль барыбызныкы да үсмер чактагыча, барыбыз да бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә сөйләшәбез. Минем партадаш кыз-әби дә теленә ирек куйган:

– Менә бу хәерсез белән, – ди миңа ымлап, – җиде ел бергә утырдык, аннары ике ел күрше авылдагы урта мәктәптә бергә укыдык, чигүле кулъяулык бүләк итеп армиягә дә озаттым мин аны. Сүз кушмый калмас әле дигән өметем дә бар иде. Юк, малай, күзе гел чит кызларда булды, – дип көлә... Без әнә шулай, онытылмас күңелле вакыйгаларны искә төшереп, көлешеп-гәпләшеп утырганда Нургаязлар кайтып төште.

– Кызлар, Сез табынны карый торыгыз, без өйлә намазын укып алабыз. Әйдәгез, кемнәр минем белән?

Без, дүрт ир-ат, башлангыч сыйныфларның бәдрәфенә кереп тәһарәт алдык та, юл аркылы гына салынган мәчеткә юнәлдек. Безгә тагын өч сыйныфташ та иярмәкче иде. Нургаяз кистереп кенә: "Тәһарәтсезләр мәчеткә керми", – дигәч, тегеләр бүленеп калды. Класс җитәкчебез Әмирҗан абый белән шунда күрештек. Ул хәзер имам-хатыйп вазыйфасын башкара икән. Озак сөйләшеп торырга вакыт булмаганлыктан, кайберләребез, минем Ише беренче тапкыр бу мәчеткә кергәннәр, мәчет намазын укырга керештек...

Аннары, сәгать икенчеләр киткәч кенә, табын артына кереп утыра алдык. Бу юлы мин алдан ук үзем сүз алып:

– Җәмәгать, минем дүтләрдән дә калмыйча юлга чыгасым бар, Актанышка чаклы биш йөз чакрым юл. Шуңа да алдан ук әйтеп куям, – дидем. "Без сине ишеттек" дигәндәй, Ринат минем якка күз сирпеп алды да мәҗлесне башлап җибәрде.

– Без башлангыч сыйныфка, Мәрьям апа, урыны оҗмахта булсын, сыйныфына 33 бала укырга кердек. Әмирҗан абый җитәкчелегендә сигезенче сыйныфны 29 укучы тәмамладык. Кызганыч, ундүртебез бүген исән түгел. Шулар рухына да дога кылып китсәк урынлы булыр иде...

Моңсу тынлыктан соң очрашу мәҗлесе безне янә балачакка алып китте, хатирәләр канвасына төшкән мәңгелек "бизәкләр" белән кабат таныштырып йөртте. Ихластан көлгән, ихтыярсыздан күзләргә яшь китергән мизгелләр аралашып барды. Без укытучыларыбызны котларга, аларның ягымлы тавышларын кабат ишетергә, мәктәп тормышыннан кызыклы вакыйгаларны искә төшерергә, бер-беребезнең тормышлары белән танышырга өлгердек. Аннары мәктәп каршында истәлек агачы утыртып, аның янында рәсемгә төштек.

Мин юлга кузгалдым. Руль артына утыргач, элегрәк музыка кушып җибәрә торган булсам, бу юлы уйларым бакыйлыкка күчкән сыйныфташларымның тормыш юлларын барладым. Әле берсе, әле икенчесе белән хәтергә уелып калган вакыйгалар күз алдыннан уза торды, озын юлның авырлыгы сизелми дә калды. Ык елгасын кичеп, Актаныш җиренә кергәндә кояш күптән баеган булса да, күк йөзенә таралган шәфәкъ кызыллыгы әле сүрелеп бетмәгән иде.

Урта мәктәптә, вузда укыган сабакташларым белән очрашкалап торабыз анысы. Ә монысы, "хәтерлим мин әле бүгенгедәй..." дигәне аеруча күңелгә якын булган икән. Нигә мин аңа баштарак игътибар итмәдем икән, белмим.

Мидхәт САДЫЙКОВ

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 7 (1920) июль 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша языла алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 01.07.2022 ел.
Тираж – 2690 Заказ О-1781

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+



Ринат АБЗАЛОВ төзеде

1. Тормышның иң бәхетле чагы?

2. Нәрсә ул хастаханә?

3. Нәрсә ул ташлама?

4. Бәхет нидән тора?

5. Иң күп кеше йөри торган күнекмәләр залы?

6. Тормыштагы иң гадәти нәрсә?

7. Эшеңә булган нәфрәтне ничек дәваларга?

ЖАВАПЛАР

1. Сине ике генә нәрсә борчыганда: тыныч вакыт һәм манный боткасы. 2. Табибларны документлар белән эшләгәндә авырулар борчый торган урын. 3. Күтәрелгән бәяләрнең вакытлыча хак рәвешкә төшүе. 4. Даруханә яныннан үткәндә бер җирең дә авыртмавы, кибет яныннан узганда бернәрсә дә кирәкмәве, чөнки синең бар әйберең дә җитенке. Өеңә кайтышың, анда сине өзелеп көтәләр. 5. Бакча. 6. Вакытлы кыенлыклар. 7. Хезмәт хакының күләмен арттыру юлы белән.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 6 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«СИН – ГОМЕР АГЫШЛАРЫМ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Б. ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Җиңүчебез – Урта Тигәнәледән **Бәдретдин ШӘЙХЕТДИНОВ!**

Вячеслав ШИЛОВ